РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru


28.05.2024 ел №248

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы регламенты турында» 2019 елның 05 июнендәге 224 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы регламенты турында» 2019 елның 05 июнендәге 224 номерлы Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 30 статьяның 5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «Район Советы утырышын ачу һәм ябу вакытында Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы һәм Чирмешән муниципаль районы гимннары яңгырый».

1.2. 36 нчы статьяның 1 нче пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «1. Район Советы утырышына материаллар депутатларга, район Башкарма комитеты җитәкчесенә, хокук иҗаты инициативасының башка субъектларына утырышка кадәр 3 көннән дә соңга калмыйча җибәрелә.

Район Советы утырышына 5 биттән артык текст күләме белән материаллар әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелгән затларга танышу өчен һәм срокларда электрон почта аша җибәрелә, тарату материалына кертелми.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (Pravo.tatarstan.ru) һәм Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чирмешән муниципаль районы Советының җирле үзидарә, Совет регламенты, хокук тәртибе, экология һәм халык иминлеге буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов